# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2007, № 2 – 3, № 11; 2010, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында һәр граждан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм халык өчен әһәмиятле функцияләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына (алга таба – органнар һәм вазыйфаи затлар) шәхсән яисә үз вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгатьләрен дә кертеп, коллектив мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.»;

2) 2 статьяның беренче өлешендә «гражданның мөрәҗәгате» сүзләреннән соң «, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгате» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяның өченче өлешендә «һәм җавап» сүзләрен «яисә җавап» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 18 октябре
№ 83-ТРЗ